# КАРАР

**6 декабрь, 2024 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге Күкшел авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 06 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге Күкшел авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр); (юлларны карап тоту Күкшел авылында урам-юл челтәре, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, проект-смета документациясе); (автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау, торба сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру); (Күкшел авылының урам-юл челтәрләренә су үткәргеч торба урнаштыру, технадзор сатып алу, ташу, урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, койма сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналары өчен насослар, материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка төр эшләр);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын, комплектлаучы детальләрне, инвентарьларны сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү);
- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (материал, инвентарь урнаштыру, сатып алу, агач кисү, киртәләрне ремонтлау, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Күкшел авылы территориясен төзекләндерү, территорияне төзекләндерүнең башка төрләре, спорт мәйданчыгын төзекләндерү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 576 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 292 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 292 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге Күкшел авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә житкән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокслы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр); (юлларны карап тоту Күкшел авылында урам-юл челтәре, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, проект-смета документациясе); (автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау, торба сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру); (Күкшел авылының урам-юл челтәрләренә су үткәргеч торба урнаштыру, технадзор сатып алу, ташу, урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, койма сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналары өчен насослар, материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка төр эшләр);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын, комплектлаучы детальләрне, инвентарьларны сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү);
- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (материал, инвентарь урнаштыру, сатып алу, агач кисү, киртәләрне ремонтлау, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Күкшел авылы территориясен төзекләндерү, территорияне төзекләндерүнең башка төрләре, спорт мәйданчыгын төзекләндерү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр).

«РИЗА» «КАРШЫ»

**кабул ителгән дип исәпләргә.**

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru Күкшел авыл җирлеге адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәмидуллин

ОГРН 1607753298
ИНН 1623002022

регистрына кертү өчен җибәрергә.